| | | |
|---|---|---|
| **РУКОВОДИТЕЛЬ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА<br>ЧЕРЕМШАНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br><br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ҖИТӘКЧЕСЕ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**10 гыйнвар 2020 ел** **Чирмешән авылы** **№ 8**

**Халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында 2020 елның I яртыеллыгына**

2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы «Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» Федераль закон нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 1 июленә кадәр расларга һәм гамәлгә кертергә:

- Чирмешән муниципаль районы муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайламаган торак урыннары милекчеләре өчен торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар (1 номерлы кушымта);
- Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак йорт белән идарә итү ысулын сайлаган күпфатирлы торак йорттагы торак урыннары милекчеләре өчен торак хезмәтләренә тәкъдим ителә торган тариф (2 номерлы кушымта))
- муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалануга база ставкасы (наем өчен база ставкасы) (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны хокукый порталда (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының беренче урынбасары Кәримов И.И. йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

1 нче кушымта
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенең 2020 елның
10 гыйнварындагы
1 номерлы карарына

**Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайламаган торак урыннарның милекчеләре өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме**

| №п/п | Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлегенә тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 |
| 2 | Торак биналарны капиталь ремонтлау (милекчеләр өчен) | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 6,11 |
| 3 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 |
| 4 | Йорт эчендәге суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 |
| 5 | Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,90 |
| 6 | Ике контурлы газ белән җылыту казаннарын техник яктан тәэмин итү | ай саен 1 газ казаны өчен | 100,0 |
| 7 | Вентиляцион каналларны тикшерү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,27 |
| 8 | Газүткәргечнең йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,21 |

2 нче кушымта
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенең 2020 елның
10 гыйнварындагы
1 номерлы карарына

**Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күпфатирлы торак йортлар белән идарә итү ысулын сайлаган торак биналарның милекчеләре өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен тәкъдим ителә торган түләү күләме**

| **№п/п** | **Түләү атамасы** | **Хезмәтне үлчәү берәмлеге** | **Хезмәтне үлчәү берәмлегенә тариф (сумнарда)** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 |
| 2 | Торак биналарны капиталь ремонтлау (милекчеләр өчен) | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 6,11 |
| 3 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 |
| 4 | Йорт эчендәге сууткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 |
| 5 | Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,90 |
| 6 | Ике контурлы газ белән җылыту казаннарын техник яктан тәэмин итү | ай саен 1 газ казаны өчен | 100,0 |
| 7 | Вентиляцион каналларны тикшерү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,27 |
| 8 | Газүткәргечнең йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,21 |

3 нче кушымта
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенең 2020 елның
10 гыйнварындагы
1 номерлы карарына

## Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалану өчен база ставкасы (наем өчен база ставкасы)

| **Түләү атамасы** | **Хезмәтне үлчәү берәмлеге** | **Хезмәтне үлчәү берәмлегенә база тарифы (сумнарда)** |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Найм буенча база ставкасы | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 6,11 |